| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| Сармановский муниципальный район | Сарман муниципаль районы |
| Совет | Петровский Завод авыл җирлеге |
| Петровско-Заводского сельского поселения | Советы |

РЕШЕНИЕ
№ 17

КАРАР
2022 ел 15 сентябрь

**Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Петровский Завод авыл җирлеге
депутаты статусы турында
нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге депутаты статусы турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (pravo tatarstan.ru) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (sarmanovo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Петровский Завод авыл җирлеге Совет рәисе А.Б.Хөснетдинов

_____
(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме һәм карары реквизитлары)*
карарына кушымта

_________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* депутаты статусы турында нигезләмә

Әлеге Нигезләмә _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* депутатының хокукларын һәм бурычларын, шулай ук депутат үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда төп хокукый һәм социаль гарантияләрне билгели.

**1 статья. _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* депутаты статусының хокукый нигезе**

1. _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* депутаты (алга таба – депутат) статусы Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары,_________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* уставы, әлеге Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

2. Җирле үзидарә органнары депутатның үз хокукларын һәм бурычларын нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

**2 статья. Депутат вәкаләтләре вакыты**

1. Депутат вәкаләтләре _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш эш башлаган көннән туктатыла, әлеге Нигезләмәнең 3 статьясында каралган очраклардан тыш.

2. Депутатның вәкаләтләре вакыты «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* уставы белән билгеләнә.

**3 статья. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә чикләнгән күләмдә генә сәләтле дип танылу;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат булган дип игълан ителү;

5) аңа карата судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

6) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгу;

7) Россия Федерациясе гражданлыгыннан яки чит ил гражданы аның нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга мөмкин булган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгыннан чыкканда, Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы Россия Федерациясе гражданы яки чит ил гражданының чит ил гражданлыгы (подданства) булганда яисә чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документы булганда;

8) сайлаучылар фикере буенча;

9) тиешле җирле үзидарә органы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яки аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрү;

11) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта;

12) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган башка очракларда.

*Искәрмә: муниципаль район советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге пункт өстәргә тәкъдим итәбез:*

*« ) аның җирлек башлыгы, муниципаль район составындагы җирлекнең вәкиллекле органы депутаты буларак вәкаләтләрен туктату.».*

2. _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, әгәр бу нигез _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы сессияләре арасында барлыкка килсә - мондый нигез барлыкка килгән көннән өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

3. Татарстан Республикасы Президенты депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып әлеге гаризаның _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* керү көне санала.

**4 статя. Депутат таныклыгы һәм күкрәк билгесе**

1. Депутат _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* депутатының шәхесен һәм вәкаләтләрен раслаучы төп документ булган таныклыкка, шулай ук үз вәкаләтләре чоры дәвамында кулланa торган күкрәк билгесенә ия.

2. Депутат таныклыгы һәм күкрәк билгесе турында нигезләмә, аларның

тасвирламасы ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* тарафыннан раслана.

**5 статья. Депутатның үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру шартлары**

1. Депутат депутат эшчәнлеген азат ителмәгән нигездә башкара, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм хезмәт вазыйфаларын башкару белән бергә алып бара, ________ (*муниципаль берәмлек исеме)* уствы белән билгеләнгән очраклардан тыш.

**6 статья. Депутат эшчәнлегенең формалары**

1. Депутат эшчәнлегенең формалары булып тора:

а) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышларында катнашу;

б) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* комиссияләре эшендә катнашу;

в) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* карауга________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* карарлары проектларын кертү;

г) депутат таләбе кертү;

д) депутат мөрәҗәгатен юллау;

е) дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм аларның вазыйфаи затларына тәкъдимнәр кертү;

ж) тиешле вазыйфаи затларга гражданнар хокукларын бозуны кичекмәстән кисәтү буенча чаралар күрүне таләп итеп мөрәҗәгать итү;

з) сайлаучылар белән эшләү;

и) депутат берләшмәләре, фракцияләр һәм депутат төркемнәре эшендә катнашу;

к) территориаль иҗтимагый үзидарә оешмаларында катнашу.

2. Депутат эшчәнлеге шулай ук федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм законнарында, ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* уставында, ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* Регламентында, башка муниципаль актларда каралган башка рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

**7 статья. Депутатның ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышында катнашуы**

1. Депутат ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышында шәхсән катнаша.

2. Депутат ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында, карауга кертелә торган мәсьәләләр турында үз вакытында хәбәр итә, шулай ук әлеге мәсьәләләр буенча барлык кирәкле материалларны ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* Регламенты нигезендә ала.

________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышында катнаша

алмаганда депутат бу хакта алдан ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының урындагы заты исеме)* хәбәр итә.

3. Депутат хокуклы:

1) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* комиссияәренә һәм тиешле вазыйфаларга сайларга һәм сайланырга;

2) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* карау өчен мәсьәләләр тәкъдим итәргә;

3) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* төзелә торган органнарны формалаштыру һәм ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* сайлый (билгеләнә, килештерелә торган) вазыйфаи затлар кандидатуралары буенча фикер белдерергә;

4) хокукый инициативаны гамәлгә ашыру тәртибендә ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* хокукый актлары проектларын кертергә;

5) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* көн тәртибенә, тикшерелә торган мәсьәләләрне карау тәртибе һәм асылы буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, карарлар проектларына һәм башка актларга төзәтмәләр кертергә;

6) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышында чираттан тыш хисапны яки ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* күзәтчелегендәге теләсә кайсы органның яисә вазыйфаи затның мәгълүматын тыңлау турында тәкъдимнәр кертергә;

7) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* Регламентында билгеләнгән тәртиптә фикер алышуларда катнашырга;

8) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышларында, аның фикеренчә, гражданнарның иҗтимагый әһәмияткә ия булган мөрәҗәгатьләрен игълан итәргә;

9) үз тәкъдимнәрен нигезләп һәм тавыш бирү мотивлары буенча чыгыш ясарга, белешмәләр һәм аңлатмалар бирергә;

10) ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышлары беркетмәләре эчтәлеге белән танышырга.

4. Депутат тарафыннан ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышында әйтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* тиешле комиссия тарафыннан карала һәм тикшерелә.

**8 статья. Депутатның ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* даими һәм вакытлы комиссияләр эшендә катнашуы**

1. Депутат ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* үзе әгъза булган комиссияләр эшендә шәхсән катнаша, тәкъдимнәр кертә, карала торган мәсьәләләр турында фикер алышуда һәм карарлар кабул итүдә катнаша.

2. Депутат үзе әгъза булмаган комиссияләр эшендә катнаша, тәкъдимнәр кертә, карала торган мәсьәләләр турында фикер алышуда һәм киңәш бирү тавышы хокукы белән карарлар кабул итүдә катнаша ала.

**9 статья. Депутатның ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* һәм аның комиссияләре йөкләмәләрен үтәүдә катнашуы**

1. Депутат үз компетенциясе кысаларында ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) һәм аның комиссияләре йөкләмәләренүтәргә тиеш.

2. Депутат ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) һәм аның комиссияләре кушуы буенча муниципаль берәмлек чикләрендә булган ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмалар тарафыннан карарларның үтәлешен тикшерүдә катнаша.

3. Йөкләмәне үтәү нәтиҗәләре турында депутат ________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) яисә аның комиссиясенә хәбәр итә

**10 статья. Депутат таләбе**

1. Депутат ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) утырышларында җирле үзидарә органнарына, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) тарафыннан булдырылган яки төзелгән башка органнар җитәкчеләренә, ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләренә, аларның компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча, депутат таләбе белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Депутат таләбе - депутат мөрәҗәгате, ул ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) карары белән депутат таләбе дип танылa. Депутат таләбе турында тәкъдим депутат яисә депутатлар төркеме тарафыннан язма рәвештә кертелә һәм ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) утырышыда ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) Регламентында билгеләнгән тәртиптә игълан ителә.

3. Депутат таләбе җибәрелгән җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат, муниципаль предприятие яки учреждение җитәкчесе аңа ___ көннән дә соңга калмыйча яки ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) тарафыннан билгеләнгән башка срокта язма формада җавап бирергә тиеш. Җавап депутат таләбе җибәрелгән орган җитәкчесе, вазыйфаи зат, муниципаль предприятие яки учреждение җитәкчесе яисә аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат тарафыннан имзаланырга тиеш.

4. Таләпнең инициаторы таләптә куелган мәсьәләләрне карауда турыдан-туры катнаша ала. Таләпнең инициаторына аларны карау көне турында алдан, әмма мәсьәләне карау көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

5. ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) җирле үзидарә органын, җирле үзидарә органының вазыйфаи затын, муниципаль предприятие яки учреждение җитәкчесен ______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) билгеләгән вакытка кабул ителгән карарның үтәлеше турында язма җавап бирүгә мәҗбүр итәргә хокуклы.

**11 статья. Депутат мөрәҗәгате**

1. Депутат мөрәҗәгате дип депутатның дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына, муниципаль предприятие һәм учреждение җитәкчеләренә, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә аларның компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча, депутат эшчәнлеге белән бәйле мәгълүмат һәм белешмәләр алу максатыннан, язмача мөрәҗәгате санала.

2. Депутат мөрәҗәгате депутат бланкында рәсмиләштерелә һәм депутат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә җибәрелә.

3. Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, аларның оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан депутат мөрәҗәгатьләрен карау гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

4. Депутат мөрәҗәгатенә җавап мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча булырга һәм мөрәҗәгать җибәрелгән вазыйфаи зат тарафыннан яисә моңа вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

**12 статья. Депутатның сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Депутат сайлау округы сайлаучылары, шулай ук предприятиеләр, оешмалар, дәүләт һәм башка органнар коллективлары белән элемтәдә тора.
2. Депутат сайлаучыларның мөрәҗәгатьләрен карый, гражданнарны кабул итә, дәүләт хакимиятенең тиешле органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм иҗтимагый берләшмәләргә тәкъдимнәр кертә, шулай ук сайлаучыларны айга кимендә бер тапкыр кабул итә.
3. Депутат сайлаучыларга үз эшчәнлекләре турында алар белән очрашулар вакытында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итә.
4. Депутат сайлаучыларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча чаралар күрә:

алардан кергән тәкъдимнәрне, шикаятьләрне карый, үз вәкаләтләре чикләрендә аларда булган мәсьәләләрне дөрес хәл итүгә ярдәм итә;

гражданнарны кабул итә;

җәмәгатьчелек фикерен өйрәнә һәм кирәк булганда тиешле дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертә.

5. Депутатларның сайлаучылар белән очрашулары махсус билгеләнгән урыннарда, биналарда, ишегалды территорияләрендә үткәрелә, аларның исемлеге һәм тәртибе ________*(урыннар һәм биналар бирү тәртибен раслаган җирле үзидарә органы исеме)* тарафыннан билгеләнгән.

Депутатның сайлаучылар белән очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә үткәрелә.

**13 статья. Депутатның депутат берләшмәләре эшендә катнашуы**

1. _______(*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме*) депутаты депутат

фракциясе яки карала торган мәсьәләләр буенча уртак эшчәнлек һәм позицияне белдерү өчен төзелә торган төркем составына керергә хокуклы.

2. Фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләрен төзү, теркәү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* регламенты белән билгеләнә.

**14 статья. Депутатның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләре**

1. Депутат _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)*, аның органнары эшчәнлегендә актив катнашуны тәэмин итә торган бөтен хокукка ия.

2. _________*(муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* депутатның аның сайлау округында башкарылган эше, _________*(муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме),* аның органнарының карарлары һәм күрсәтмәләрен үтәве турындагы мәгълүматын тыңларга хокуклы.

3. Җирле үзидарә органнары һәм аның вазыйфаи затлары депутатка аның эшендә кирәкле ярдәм күрсәтәләр, депутатка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге, икътисади һәм социаль үсеш программаларын үтәүнең барышы, депутатның тәнкыйди кисәтүләре һәм тәкъдимнәре буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат бирәләр, депутатка законнарны, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары эш тәҗрибәсен, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүгә ярдәм итәләр.

**15 статья. Депутатның вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителүгә хокукы**

Депутат үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча _________*(муниципаль берәмлек исеме)* җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, оешмаларның, муниципаль милек рәвешендәге учреждениеләрнең вазыйфаи затлары тарафыннан чираттан тыш кабул ителү хокукыннан файдалана.

**16 статья. Депутатның мәгълүмат алу һәм тарату хокукы**

Депутат җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль оешмалардан һәм аларның вазыйфаи затларыннан депутат эшчәнлеге белән бәйле, закон тарафыннан сер буларак сакланмый торган мәгълүмат алу хокукына ия.

**17 статья. Депутат бурычлары**

1. Депутат бурычлы:

1) үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын, шәһәр уставын, башка муниципаль хокукый актларны үтәү;

2) гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне һәм яклауны тәэмин итү;

3) даими нигездә, кимендә айга бер тапкыр, сайлаучыларны кабул итү;

4) гражданнарның, аларның оештыру-хокукый формасына карамастан оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карау һәм аларга үз

компетенциясе чикләрендә җавап бирү;

5) сайлаучылар алдында очрашуларда елга бер тапкырдан да ким булмаган санда хисап тоту;

6) депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләрне үтәү;

7) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны үтәү;

8) әхлак һәм депутат этикасы нормаларын үтәү;

9) дәүләт серен һәм закон тарафыннан саклана торган башка серләрне саклау, шулай ук гражданнарның шәхси тормышына, намусына һәм абруена кагылышлы, депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә аңа билгеле булган белешмәләрне таратмау;

10) ел саен хисап финанс елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру.

2. Депутат үзенә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шәһәр Уставы һәм башка муниципаль хокукый актлар белән йөкләнгән башка бурычларны башкара.

**18 статья. Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр**

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутат хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) түләүсез нигездә катнашу;

б) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәр итү тәртибендә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән (сәяси партия идарәсендә, һөнәр берлеге органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органында, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында яки съездда (конференция) катнашудан тыш) идарә итүдә катнашу;

в) муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы Ассоциациясенә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләренә, шулай ук аларның идарә органнарында тәкъдим итү;

г) идарә органнарында һәм гамәлгә куючысы (акционеры) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясе алдында түләүсез нигездә муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финансланырга тиеш түгел;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керергә.

2. Даими нигездә вәкаләтләр башкаручы депутат граждан административ яки җинаять эше буенча яки административ хокук бозу турында эш буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак катнаша алмый.

**19 статья. Депутат этикасы**

1. Депутат закон, этика һәм әхлак нормаларын да катгый үтәргә тиеш, шул исәптән:

1) _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* утырышларда билгеләнгән дисциплина һәм регламентны үтәргә;

2) депутат вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә мөнәсәбәтләргә керә торган башка депутатлар, вазыйфаи затлар һәм гражданнарга карата түземлек һәм хөрмәт күрсәтергә;

3) депутат вәкаләтләрен үтәү белән бәйле рәвештә аңа билгеле булган мәгълүматларны депутат эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда кулланмаска һәм таратмаска, әгәр бу мәгълүматлар дәүләт, хезмәт, коммерция серен, шәхси яки закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итсәләр;

4) җирле үзидарә органнары эшендә катнашудан тыелырга һәм шәхсән яки аның якыннарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар эшчәнлегенә, вазыйфаи затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм гражданнарга йогынты ясау өчен депутат статусыннан файдаланмаска;

5) депутат вазыйфаларын объектив башкаруда шик тудырырлык гамәлләр, гаризалар, эшләр, шулай ук аның абруена яисә _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* зыян китерә торган конфликтлы ситуацияләрдән тыелырга;

6) вазыйфаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык туганда, бу хакта муниципаль берәмлекнең

вәкиллекле органы карары белән расланган тәртиптә _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* хәбәр итәргә һәм аның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга юнәлтелгән карарларын үтәргә;

7) _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* билгеләнгән гавами чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә.

2. Депутат этикасы бозылган очракта депутатның үз-үзен тотышы турындагы мәсьәлә _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* кушуы буенча тиешле комиссия тарафыннан карала.

**20 статья. Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыру гарантияләре**

1. Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруның матди һәм башка гарантияләре законнар, _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* уставы, _________ (*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме)* муниципаль норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Депутат хокукларының гарантияләре, аларны җинаять яки административ җаваплылыкка тарту, тоткарлау, арест, тентү, сорау алу, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылу очракларында, шулай ук аларның торак һәм (яки) хезмәт урынын, аларның багажын, шәхси һәм хезмәт транспорт чараларын, алар тарафыннан кулланыла торган элемтә чараларын тикшергәндә, федераль законнар белән билгеләнә.

3. Депутат әйтелгән фикере, тавыш биргәндә белдерелгән позициясе өчен һәм аның статусына туры килә торган башка гамәлләре өчен җинаять яки административ җаваплылыкка тартыла алмый, шул исәптән аның вәкаләтләре вакыты чыккач та. Әлеге нигезләмә депутат тарафыннан халык алдында мыскыл итү, яла ягу яки федераль закон белән каралган башка хокук бозу очракларына кагылмый.

---